Проект


**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2018 № 879

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 июлендәге 510нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы звеносы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында” 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 июлендәге 510нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы звеносы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12нче пунктта:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“күрсәтелгән хезмәтләр тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган объектларда һәм территорияләрдә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планы нигезендә;”;

б) өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 21нче пунктның алтынчы абзацында “буенча эшләр” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 23нче пунктта:

а) “а” пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әйләнә-тирәлек торышын өйрәнү, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерергә сәләтле куркыныч табигать күренешләренә һәм техноген процессларга мониторинг үткәрү, гадәттән тыш хәлләрне фаразлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;”;

б) “а” пунктчасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“халыкны гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә, шул исәптән ашыгыч хәбәр итү сигналларын алган вакытта хәрәкәтләргә әзерләү;”;

в) “б” пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әйләнә-тирәлекнең торышына контрольне көчәйтү, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерергә сәләтле куркыныч табигать күренешләренә һәм техноген процессларга мониторинг үткәрү, гадәттән тыш хәлләрне фаразлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;”;

г) “б” пунктчасының алтынчы абзацында “(үзара хезмәттәшлек)” сүзләрен төшереп калдырырга;

д) “в” пунтчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әйләнә-тирәлек торышын өзлексез тикшереп тору, барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр үсешен мониторинглау һәм прогнозлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;”;

е) “в” пунктчасын түбәндәге реадкциядәге абзац белән тулыландырырга:

“халыкка гадәттән тыш хәлләр, аларның параметрлары һәм зарар китерә торган факторлар, халыкның һәм территорияләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар, гадәттән тыш хәл зонасында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм зыян күрүчеләрне социаль яклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары турында, шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган түләүләрне алу хокукы турында, гадәттән тыш

хәлләр нәтиҗәсендә югалган документларны торгызу тәртибе турында мәгълүмат бирү.”;

4) 26нчы пунктның икенче абзацында “эшләр җитәкчеләренең вәкаләтләре” сүзләрен “җитәкчеләрнең вәкаләтләре” сүзләренә, “буенча эшләр җитәкчеләре килеп җитү” сүзләрен “җитәкчеләрнең килүе” сүзләренә, “кисәтмә” сүзен “кисәтү буенча эшләр” сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Р.В. Михеев